# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге муниципаль берәмлегенә кергән Аграмак торак пунктында 2024 елга үзара салым кертү турында

25.10.2023ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлегегенә кергән Аграмак торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАРЫ:

1.Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлегегенә кергән Аграмак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Аграмак торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам утларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Аграмак торак пунктында юлларны кардан чистарту, грейдерлау (ягулык – майлау материаллары, МТЗ-82 тракторына запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Аграмак торак пунктында рөхсәтсез барлыкка килген чүплекләрне бетерү (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- янгын сүндерү машинасын карап тоту (янгын сүндерү машинасына запас частьләр сатып алу);

3. Әлеге карарны Аграмак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм http:// www. spasskiy.tatarstan.ru Спас муниципаль районы рәсми сайтының Аграмак авыл җирлеге битендә, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Спас муниципаль районы
Аграмак авыл җирлеге башлыгы: Р.Т. Галәветдинова

СОВЕТ АГРАМАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ